КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 5 май г.Казань № 666

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 май, 431 нче карары белән расланган Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә куйганда эшсез гражданнарга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә куйганда эшсез гражданнарга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 311 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 863 нче; 2020 ел, 3 август, 645 нче; 2021 ел, 20 сентябрь, 885 нче, 2022 ел, 29 март, 287 нче, 2022 ел, 13 август, 817 нче, 2023 ел, 10 февраль, 124 нче, 2023 ел, 18 март, 278 нче, 2023 ел, 06 ноябрь, 1424 нче, 2024 ел, 30 гыйнвар, 44 нче, 2024 ел, 6 апрель, 236 нчы, 2024 ел, 24 август, 692 нче, 2025 ел, 24 февраль, 111 нче, 2025 ел, 3 декабрь, 1034 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче

буларак салым органында исәпкә куйганда эшсез гражданнарга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә, 2.1 пунктның беренче абзацында «145 100» саннарын «250 000» саннарына белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин